

podpiska.pochta.ru

# «ТУГАН ШӘҺӘРЕҢНӘН КИТҮ МӘҖБҮРИ ТҮГЕЛ»

Автор / Динара Зиннәтова
Тәрҗемә / Гүзәл Закирова

**«Инсайт Люди» продюсерлык үзәге генераль директоры Алинә Зиннәтуллина белән блогерларның җәмгыятьтәге урыны, микроинфлюенсерлар чоры һәм Россиядәге контент җитештерүдәге трендлар турында сөйләштек.**

**«Кыюлык җыя алмаган булсам, бәлки әле дә икеләнеп йөрер идем»**

**– Сезнең блогинг юнәлешенә ничек килеп эләгүегезне беләсе килә.**

– Мин Казан федераль университетында юриспруденция юнәлешендә белем алдым һәм үз белгечлегем буенча судта эшләдем. Әмма күпмедер вакыттан соң бу эшкә күңелем ятмавын аңладым. Тормышымны кинәт кенә бөтенләй башка якка үзгәртү куркытты, әлбәттә, әмма ул вакытта кыюлык җыя алмаган булсам, бәлки әле дә икеләнеп йөрер идем. SMM, продюсерлык – төрле юнәлешләргә алынып карадым, әмма елдан-ел популярлаша барган блогинг ныграк кызыктырды. Блогерлык агентлыгы оештыру идеясе болайрак туды: безнең команда бер чарага күпләп инфлюенсер чакырырга тиеш иде. Шул мәлдә без: «Төбәкләрдә иҗат итүче блогерларны да берләштерерлек компания ясасак, ничек булыр иде икән?» – дип уйладык. Тәүге нокта шул булгандыр, мөгаен, һәм ул безнең тормышыбызны үзгәртте дә куйды. Хәзер «Инсайт Люди» продюсерлык үзәгенең генераль директоры буларак минем эшем блогинг белән тыгыз бәйләнгән.

Фотолар геройның шәхси архивыннан

podpiska.pochta.ru

# БЮДЖЕТЛЫ СӘЯХӘТЧЕ КӨНДӘЛЕГЕ: ӨЧ ИЛГӘ 50 МЕҢГӘ

Автор / Зөләйха Камалова

**Мин сәяхәт итәргә бик яратам, ә акча түгәргә – юк. Шуңа сәяхәтләремне мөмкин кадәр бюджетлы итәргә тырышам. Еш кына якындагы чит илгә барып кайту Россия эчендә сәяхәт итүгә караганда арзанрак килеп чыга.**

**Быел мин өч дәүләттә булып кайттым. Юл чыгымнарын да исәпләп, бер атналык сәяхәт бер кешегә 50 мең сумнан кимрәк килеп чыкты.**

## Азәрбайҗан

Туризм өчен иң рәхәт вакыт май урталарыннан октябрь азакларына хәтле (җәй уртасы эссе яратучыларга гына туры килә). Азәрбайҗанга барсаң, сине шәһәр ялы көтә, ягъни иркенләп диңгез буенда ятып булмаячак. Билгеле, Каспий диңгезе бар, әмма махсус җайланган пляжлар юк диярлек. Җирле халык монда су керми, чөнки Каспий төбеннән азәрбайҗаннар нефть таба. Нефть – илне яшәтә торган төп ресурс. Илнең башкаласы Баку шәһәрендә нефть суырткычлары шәһәр уртасында ук тора, кайбер урыннарда араларыннан парктагы сыман йөрергә мөмкин.

Баку – бик матур, чиста, яшел шәһәр. Башкаланың яңа гына төзелгән сәер архитектуралы күктиярләре дә, XII гасырда ук таштан төзелгән тар иске урамнары да бар. Иске шәһәрне бакулылар «Ичери Шехир» дип, ягъни эчке шәһәр дип атыйлар. Анда кешеләр хәзергәчә яши. Азәрбайҗан халкы ачык һәм кунакчыл. Таныш булмаган кешеләр дә кунакка чәйгә чакыра. Иске шәһәрдәге бер йортка кунакка чакыруны кабул иттем. Йорт хуҗасы – өлкән яшьтәге бер абзый, гомер буе журналист булып эшләгән булып чыкты. Тормышы турында сорашкач, йортын күрсәтте, гаиләсе турында сөйләде. Азәрбайҗанда күпчелек халык ярлы яши, шуңа карамастан күбесе үзен бәхетле дип саный. Иң борчылганнары: акча җитмәү, эш булмау, Әрмәнстан белән булган сугыш...

Иң нык тәэсир иткәне Баку яшьләре булды. Без танылган Азәрбайҗан джазын тыңлау нияте белән йөргәндә, урамда торган фортепианога юлыктык. Бик тиздән бу безнең иң яраткан урынга әйләнде. Монда һәркөн яшьләр җыела. Аларның күбесе музыка коралларында уйный һәм бик матур итеп җырлый.



podpiska.pochta.ru

# АРЧАЛЫЛАР СТИЛЕ

Автор / Гүзәл Закирова



**Күпләрегез яратып өлгергән «Стилист – авылда» проектының өченче чыгарылышын Арча районында төшердек. Бу җирлекнең үзенчәлеге - монда яшьләр гадәттә шоурумнарда киенә.**

podpiska.pochta.ru

# ТАТАРЧА ХОРРОР: ТАТАР МӘДӘНИЯТЕНДӘГЕ КУРКЫНЫЧ РУХЛАР

Автор / Зөләйха Камалова

**Хэллоуин якынлаша. Шомлы бәйрәмгә кем булып киенергә? Граф Дракула, әллә зомбимы? Юк ла инде, татарның үзенең дә менә дигән «коточкыч» җан ияләре һәм явыз рухлары бар бит. Төркиләрдә булган куркыныч мифик затлар – җен-пәриләрне барлыйк әле.**



***Раса:*** *урман иясе*
***Шөгыль:*** *урманны саклый, кешеләрне кытыклый*
***Ничек җиңәргә:*** *суда батырырга яки яндырырга*
***Супер көче:*** *супер тизлек*

## Шүрәле

*Ялтырый, ялт-йолт киләдер эчкә баткан күзләре,*
*Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе;*
*Урта бармак буйлыгы бар маңгаенда мөгезе.*

Тукай язган Шүрәле халыкта элек тә булган. Бөек язучыбыз балалар психикасын җәрәхәтләргә теләмәгәнме, Шүрәленең кыяфәтен сурәтләгәндә, халык мифларында берничә мәртәбә телгә алынган бер детальне төшереп калдырган: Шүрәленең озын мөгезе һәм озын борынынннан кала, бик озын күкрәкләре дә бар. Кайбер чыганаклар буенча, ул аларны хәтта җилкәсе аша ташлый алган.

Шүрәле – кап-кара урманда яшәүче җенессез кара рух. Ул урманда ялгыз йөрүче кешеләргә иярә. Башта адашкан кеше булып кылана, юл сорашырга мөмкин. Кеше тынычлыгын җуйдымы, аны урман эченә алып кереп адаштыра һәм озын бармаклары белән кытыклый башлый, үлгәнче көлдерә. Ерак араларны бик тиз уза,



poltjeska.pochta.ru

# ШАГЫЙРЬЛӘР ГАШЫЙКЛЫК ТУРЫНДА СӨЙЛИ

Автор / Гүзәлә

**«19 сентябрь көнне «МОҢ» театраль мәйданчыгын гашыйклык хисе урап алачак» диелгән иде афишаларда. Шулай булды да! Кичәдән соң Казанда гашыйк булырга теләүчеләр саны да чак кына артты бугай. «Йокмый йокым» дип аталган кичәдә сөю хисенә пропаганда ясадык.**

Болайрак булды ул: өч шагыйрә – Миләүшә Гафурова, Айгөл Хәбибрахманова һәм мин гашыйклык турында шигырьләребезне укыдык. Алсу Мансурова, Элина Ситдыйкова һәм Илгиз Мөхетдинов шигырьләр арасында үзләренең хисле, назлы җырларын башкарды. Ә Марат Шаяхмәтов белән Тимур Милюков чараның гомуми вайбы, музыкаль бизәлеш өчен җаваплы иде.



Үзем бу язманы язып утырам, үзем аптырыйм – нишләп шундый коры сүзләр генә телгә килә соң минем... Шундый хисле, дәртле, күңелне актарып чыгарырдай кичә эшләдек бит югыйсә! «Йокмый йокым»да без 70 пар күз каршында «шәп-шәрә» идек, бер сәгать буе кайчандыр аяк астыннан туфракны юк иткән гашыйклыгыбыз кайтавазында өедык, аннары тамашачыларны кочтык та... хәлсезләнеп гримеркага кереп егылдык. Һәрберебез үз гашыйклыгын яңадан кичерде һәм үзе өчен ниндидер нәтиҗә ясады.



podpiska.pochta.ru


# «БИЕ-БИЕ, ХӘЙБУЛЛА»

**«ИДЕЛ» журналында «Алло, Илһам!» проекты да эшләп килә. Аның кысаларында яңа шигырьләр, җырлар яздырабыз, кызыклы видеолар һәм хәтта клиплар да төшерәбез.**





**Шундый клипларның берсендә татар фольклор такмагына яңа сулыш өрергә булдык. Татарча аңлый торган нейрочелтәрдән «Бие-бие, Хәйбулла...» такмагын язып бетерүен сорадык һәм заманча трек ясаттык.**



podpiska.pochta.ru